# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Советы

Татар Шуганы авылы №163 «21» гыйнвар 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Советының 2010 елның 14 апрелендәге 118 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлегенең бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү хакында (12.11.2010, №6, 29.10.2011 №31, 30.10.2013 №73, 08.08.2014 №110, 29.10.2015 №11, 27.06.2017 №57, 13.11.2017 №72, 03.09.2019 №146, 16.12.2019 №157 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлегендә бюджет процессы Нигезләмәләрен Россия Федерациясенең гамәлдәге бюджет законнарына туры китерү максатында

Татар Шуганы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Советының 2010 елның 14 апрелендәге 118 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлегенең бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә (12.11.2010, №6, 29.10.2011 №31, 30.10.2013 №73, 08.08.2014 №110, 29.10.2015 №11, 27.06.2017 №57, 13.11.2017 №72, 03.09.2019 №146, 16.12.2019 №157 карарлар редакциясендә) түбәендәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә, 1 бүлекнең 8 статьясындагы 4 пунктының тугыз абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-бирелгән гарантияләрнең исәбен, алар буенча муниципаль бурычны арттыру, принципаллар йә еченче затлар тарафыннан тулы күләмдә яисә гарантияләр белән тәэмин ителгән принципал йөкләмәләренең нинди дә булса өлешендә муниципаль бурычны киметү, принципал йекләмәләренең тулы күләмдә яисә нинди дә булса елешендә туктатылу, гарантияләр белән тәэмин ителгән принципал йөкләмәләренең нинди дә булса өлешендә, шулай ук муниципаль гарантияләрдә билгеләнгән башка очракларда муниципаль бурычны киметүне алып бара;».

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatar.ru. урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, финанслар, салымнар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.З.Мияссәрова